**КАРАР**

**Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбья авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**21 ноябрь 2022 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 21 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар (курсантлар), I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбия авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 2100 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Яңа Чәбия авылы территориясен төзекләндерү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү);
- Җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета төзү);
- Яңа Чәбия авылында урнашкан чишмәне төзекләндерү (смета документларын эшләү һәм түләү, чыгым материалларын сатып алу һәм ташу, килешү һәм техник күзәтчелек буенча эшләр өчен түләү);
- Вак таш сатып алу (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү);
- Елга аша басма кую (смета документларын эшләү һәм түләү, чыгым материалларын сатып алу һәм ташу, килешү һәм техник күзәтчелек буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 38 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 23 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 23 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбья авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар (курсантлар), I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә

чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбия авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 2100 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Яңа Чәбия авылы территориясен төзекләндерү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү);
- Җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета төзү);
- Яңа Чәбия авылында урнашкан чишмәне төзекләндерү (смета документларын эшләү һәм түләү, чыгым материалларын сатып алу һәм ташу, килешү һәм техник күзәтчелек буенча эшләр өчен түләү);
- Вак таш сатып алу (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү);
- Елга аша басма кую (смета документларын эшләү һәм түләү, чыгым материалларын сатып алу һәм ташу, килешү һәм техник күзәтчелек буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»?»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Нырты авыл җирлеге башлыгы: Т. А. Котдусов

ОГРН 1021607754563
ИНН 1623001710